# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлегенең Приозерная авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча**

18 декабрь 2021 е. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге составына керүче Приозерная авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, моңа 1 төркем инвалидлар, студентлар, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнар керми, һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү:
- җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- торак пунктларда урамнарны яктыртуны карап тоту;
- су белән тәэмин итү челтәрләрен карап тоту;
2. Әлеге карарны Зирекле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районының
Зирекле авыл җирлеге башлыгы В.А.Данилова